## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“14” ноябрь 2021 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 15 ноябрендә «Сез 2022 елда Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Авыл җирлеге биләмәсе территориясен чистарту тәртипләрен раслау, аларның үтәлешен тәэмин итү, территорияне төзекләндерүне билгеләнгән кагыйдәләргә таянып оештыру:

- Югары Сәрдә авылы территориясендәге агач һәм куакларны кисү, чистарту;

-Югары Сәрдә авылы территориясендәге чишмәгә илтүче күперне төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм чишмә тирәсен яңарту

2. Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

- Югары Сәрдә авыллы зираты территориясендәге агач һәм куакларны кисү, чистарту;

- Югары Сәрдә авыллы зираты коймасы өчен төзелеш материалары һәм буяулар сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 139 (йөз утыз тугыз) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 94(туксан дүрт) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 94(туксан дүрт) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2022 елда Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

1. Авыл җирлеге биләмәсе территориясен чистарту тәртипләрен раслау, аларның үтәлешен тәэмин итү, территорияне төзекләндерүне билгеләнгән кагыйдәләргә таянып оештыру:

-Югары Сәрдә авылы территориясендәге агач һәм куакларны кисү, чистарту;

-Югары Сәрдә авылы территориясендәге чишмәгә илтүче күперне төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу һәм чишмә тирәсен яңарту

2. Күмү урыннарын төзекләндерү һәм карап тоту:

-Югары Сәрдә авыллы зираты территориясендәге агач һәм куакларны кисү, чистарту;

-Югары Сәрдә авыллы зираты коймасы өчен төзелеш материалары һәм буяулар сатып алу.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы Хуснутдинов Р.Р.